Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге Кече Кибәче торак пунктында

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

02.11.2019 № 1

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге Уставының 22 нче маддәсенә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге Советының 25.10.2009 ел, № 19 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында " карарына таянып, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлегенең Кече Кибәче торак пункты территориясендә халык җыены карар итте:

1. 2020 нче елда Саба муниципаль районының Олы Кибәче авыл җирлеге Кече Кибәче торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- Кече Кибәче авылында Бөек Ватан сугышы ветераннарына һәйкәлне карап тоту.

3.Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru/kibiachi бастырып чыгарырга.

Җыенда рәислек итүче:
Олы Кибәче авыл
җирлеге башлыгы А.К. Сафин